**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 июль № 517

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 15 апрель, 187 нче; 2006 ел, 2 август, 396 нчы; 2007 ел, 12 октябрь, 549 нчы; 2009 ел, 2 март, 117 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 657 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1036 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 534 нче; 2011 ел, 25 октябрь, 887 нче; 2013 ел, 18 март, 178 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 858 нче; 2014 ел, 7 февраль, 70 нче; 2014 ел, 20 май, 336 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 970 нче; 2015 ел, 5 июнь, 422 нче; 2015 ел, 9 декабрь, 929 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче; 2016 ел, 14 июль, 480 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«боерык белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүне гамәлгә ашыра;

ведомство бүләкләрен гамәлгә куя, алар белән бүләкләү турында карарлар кабул итә һәм халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклауны, янгын куркынычсызлыгын, су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итүгә, шулай ук гражданнар оборонасы мәсьәләләрен хәл итүгә өлеш керткән гражданнарны бүләкләүнең бүтән төрләрен куллана.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков